| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОСЛЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ЭСЛӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.11.2019 Иске Эсләк авылы номер 12

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Башкарма комитетының “Беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм катнашулары хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле булган башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү турында аерым категория затларның хәбәр итүе тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2019 елның 2 октябрендәге 8 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законга нигезләнеп, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Башкарма комитетының “Беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм катнашулары хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле булган башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү турында аерым категория затларның хәбәр итүе тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2019 елның 2 октябрендәге 8 номерлы карарның үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләренең әлеге карары белән таныштырырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

И.Н.Гафаров